| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КИЯТСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КАРЛЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 11.01.2023 | № 2 |

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 июлендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Буа муниципаль районының Карлы авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Буа муниципаль районы Карлы авыл җирлегеге башкарма комитетының 2022елның 4 апрелендәге 8 номерлы «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Регламентның 3.3.2.1. пунктының 11 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Формалаштырылган гаризаны формаль-логик тикшерү мөрәҗәгать итүче һәр кырның электрон формасы кырларын тутыру процессында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла.Бердәм портал тарафыннан корректлы тутырылган электрон формасы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны юкка чыгару тәртибе турында мөрәҗәгатьнең электрон формасында ук мәгълүмат аша хәбәр итә.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы Карлы авыл
җирлегеге башкарма комитеты җитәкчесе Д.Х. Абдрахманов